Ошторма-Юмья авыл җирлеге Советы

КАРАР

2019 елның 28 ноябре №33

«Җир салымы турында» 2013 елның
25 ноябрендәге 20 номерлы
Ошторма-Юмья авыл җирлеге Советы карарына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Ошторма-Юмья авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Җир салымы турында» 2013 елның 25 ноябрендәге 20 номерлы Ошторма-Юмья авыл җирлеге Советы карарына (Ошторма-Юмья авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 39 номерлы, 2015 елның 30 маендагы 23 номерлы, 2015 елның 18 ноябрендәге 11 номерлы, 2017 елның 27 июнендәге 17 номерлы, 2018 елның 14 ноябрендәге 29 номерлы, 2018 елның 29 ноябрендәге 33 номерлы, 2018 елның 20 декабрендәге 33 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) кадастр бәясеннән 0,1 процент – торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына карамый торган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлешләрдән тыш) яки торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) (эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган шәхси торак төзелеше өчен алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) җир кишәрлекләренә карата;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, шулай ук Ошторма-Юмья авылы җирлеге торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән соң кимендә бер ай узгач, үз көченә керә.

Ошторма-Юмья авыл
җирлеге башлыгы урынбасары: М.М. Егорова